МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

16.11.2021 №419

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү һәм үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү, рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 20 февралендәге 57 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү һәм үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү, рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 20 февралендәге 57 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 24.12.2018 №646, 10.03.2020 №81, 08.06.2020 №921, 15.03.2021 №112, 25.06.2021 №241 реквизитлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Ф.М. Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгының 16.11.2021
№419 реквизитлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү һәм үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү, рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 20 февралендәге 57 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерыкта:

боерыкның аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү һәм үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү, рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлекнең 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү)

2.2. Башкарма хакимият органы исеме.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау.

1. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт (алга таба – рөхсәт).

2. Рөхсәт дубликаты.

3. Үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт.

4. Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату.

5. Рөхсәт бирүдән, аны үзгәртеп рәсмиләштерүдән һәм рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктатудан баш тарту.

Рөхсәт җиңел такси сыйфатында кулланыла торган һәр транспорт чарасы өчен 5 (биш) елга бирелә.

Рөхсәт Министрлык бланкында рәсмиләштерелә (999 номерлы ТР МК карары белән расланган форма буенча).

Рөхсәт дубликаты рөхсәт бланкында «дубликат» һәм «рөхсәтнең оригиналы гамәлдә түгел» тамгалары белән рәсмиләштерелә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

Рөхсәтне бирү гаризаны теркәгәннән соң дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү гаризаны теркәгәннән соң дүрт эш көне эчендә башкарыла.

Рөхсәт дубликатын бирү гаризаны теркәгәннән соң дүрт эш көне эчендә башкарыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Рөхсәт бирүдән баш тарту гаризаны теркәгәннән соң дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктатудан баш тарту гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) мөрәҗәгать иткән көнне рөхсәтләр бирү графигы нигезендә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү күздә тотылмаган.

2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе.

2.5.1. Рөхсәт алу өчен түбәндәгеләрне тапшырырга:

а) рөхсәт бирү турында гариза, үз эченә алган түбәндәге мәгълүматларны ала:

юридик затлар өчен тулы һәм кыскартылган (булган очракта) исеме, шул исәптән юридик затның фирма атамасы һәм оештыру-хокукый рәвеше, аның урнашу урыны адресы, юридик зат төзү турындагы язуны дәүләт теркәвенә алу номеры, юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат турында белешмәләр кертү фактын раслаучы документ белешмәләре, дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы органның урнашу урынын күрсәтеп, шулай ук телефон номерын һәм (булган очракта) юридик затның электрон почта адресы (2 нче кушымта);

шәхси эшкуарлар өчен фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме, яшәү урыны буенча теркәлү адресы, аның шәхесен таныклаучы документ белешмәләре, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турындагы язуны дәүләт теркәвенә алу номеры, шәхси эшкуар турындагы мәгълүматларны шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертү фактын раслаучы документ белешмәләре, дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы органның урнашу урыны адресын күрсәтеп, шулай ук телефон номеры һәм (булган очракта) шәхси эшкуарның электрон почта адресы (3 нче кушымта);

салым түләүченең тәңгәллек саны һәм салым органында салым түләүченең исәпкә куелуы турындагы документ белешмәләре;

б) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

в) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасын теркәү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган таныклык күчермәсе;

г) лизинг шартнамәсенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтү өчен файдалану күздә тотыла торган транспорт чарасы белән лизинг турындагы шартнамә шартларында идарә иткән очракта);

яисә файдалануга алу шартнамәсенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтү өчен файдалану күздә тотыла торган транспорт чарасы белән файдалануга алу турындагы шартнамә шартларында идарә иткән очракта);

яисә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәтү өчен шәхси эшкуар тарафыннан транспорт чарасы белән эш итү хокукына нотариаль расланган ышанычнамә күчермәсе (транспорт чарасы физик зат тарафыннан транспорт чарасы белән эш итү хокукына нотариуста расланган ышанычнамә нигезендә бирелгән очракта).

2.5.2. Рөхсәт дубликатын алу өчен түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

а) юридик затлар (4 нче кушымта) яки шәхси эшкуарлар (5 нче кушымта) өчен рөхсәт дубликаты бирү турында гариза;

б) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

в) рөхсәт кәгазе бозылган очракта, рөхсәт дубликаты бирү турындагы гаризага бозылган рөхсәт кәгазе теркәлә.

2.5.3. Рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

а) юридик затлар өчен (6 нчы кушымта) яки шәхси эшкуарлар өчен (7 нче кушымта) рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза, анда түбәндәгеләр турында

белешмәләр күрсәтелә:

мөрәҗәгать итүче яисә аның әлеге Регламентның 2.5 пунктының 2.5.1 пунктчасының «а» пункты өлешендә каралган хокуклы варисы турында (юридик зат үзгәртелеп корылган очракта);

юридик затның исеме яисә аның урнашу урыны (юридик затның исеме һәм урнашу урыны үзгәргән очракта);

шәхси эшкуарның яшәү урыны, фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхси эшкуарның шәхесен таныклаучы документ белешмәләре (шәхси эшкуарның яшәү урыны, фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхси эшкуарның шәхесен таныклаучы документ белешмәләре үзгәргән очракта);

җиңел такси сыйфатында кулланыла торган транспорт чарасының яңа дәүләт теркәү билгесе (җиңел такси буларак файдаланыла торган транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесе үзгәргән очракта);

б) мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документының мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәсе;

в) җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәтү өчен файдалану күздә тотылган транспорт чарасын теркәү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган таныклык күчермәсе;

г) гамәлдәге рөхсәтнең оригиналы;

д) лизинг шартнамәсенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтү өчен файдалану күздә тотыла торган транспорт чарасы белән лизинг турындагы шартнамә шартларында идарә иткән очракта);

яисә файдалануга алу шартнамәсенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәсе (җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтү өчен файдалану күздә тотыла торган транспорт чарасы белән файдалануга алу турындагы шартнамә шартларында идарә иткән очракта);

яисә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәтләр күрсәтү өчен транспорт чарасы белән эш итү хокукына нотариаль расланган ышанычнамә күчермәсе (транспорт чарасы физик зат тарафыннан транспорт чарасы белән эш итү хокукына нотариуста расланган ышанычнамә нигезендә бирелгән очракта).

2.5.4. Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату өчен түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

а) рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында гариза (8 нче кушымта);

б) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (мөрәҗәгать итүче вәкиле эш иткән очракта) (шәхси эшкуарлар яки юридик затлар өчен);

в) транспорт чарасын теркәү турында таныклыкның расланган күчермәсе (гариза транспорт чарасы хуҗасы тарафыннан бирелгән очракта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар мөрәҗәгать итүче (яки аның вәкиле) тарафыннан Министрлыкка турыдан-туры кәгазь чыганакларда, тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы юллама белән яки электрон формада, Портал яки Бердәм портал аша, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, тапшырыла (җибәрелә).

Рөхсәт бирү турында гариза шулай ук КФҮ аша да, ерактагы эш урыны аша да тапшырылырга мөмкин.

Гаризаны турыдан-туры тапшырганда яки аны почта аша җибәргәндә гаризага мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар теркәлә.

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта, аңа сорала торган документларның сканер аша уздырылган күчермәләре теркәлә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

почта юлламасы белән;

КФҮ аша;

күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә «Интернет» челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны Портал яисә Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган электрон документ үрнәкләрен яки электрон формадагы документларны тапшыра.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:

а) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (Россия Федераль салым хезмәтендә).

б) Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (Россия Федераль салым хезмәтендә).

в) Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләүне раслаучы акчаларның алынуы турында турында белешмәләр (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсендә).

г) Рөхсәт алу өчен белдерелгән транспорт чарасы турында белешмәләр (Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе органнарында).

д) Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләр (Россия Эчке эшләр министрлыгы органнарында).

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документларны алу ысуллары һәм тәртибе, ул тапшырырга тиешле документларның исемлеге әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре танылканган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

а) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасы тапшырылганда;

б) Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар үз көчләрен югалткан очракта.

в) Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар текстында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә танылканмаган чистарту һәм төзәтү урыннары булган очракта.

г) Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булган очракта.

д) Гариза формасында, шул исәптән Порталда һәм Бердәм порталда гаризаның интерактив формасында, кырларның тулысынча тутырылмавы;

е) «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чын булуын тану шартларын үтәмәү очрагы ачыкланган очракта.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Порталда яки Бердәм порталда урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

2.8.1. Рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр тапшыруы тора, шул исәптән:

а) гаризада һәм аңа теркәп тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булуы;

б) мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклаучы затның вәкаләтләрен раслаучы

документларда белешмәләрнең дөрес булмавы;

в) мөрәҗәгать итүче биргән документларда һәм белешмәләрнең ведомствоара электрон багланышлар нәтиҗәсендә алынган белешмәләрдә булган мәгълүматка туры килмәве;

г) мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләрнең бирелгән рөхсәтләр реестры мәгълүматларына туры килмәве (транспорт чарасына элегрәк бирелгән, гамәлдәге рөхсәт булуы);

д) мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затлар даирәсенә туры килмәве.

2.8.2. Рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризада һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документларда тулы һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат булуы;

транспорт чарасына элегрәк бирелгән гамәлдәге рөхсәтнең булмавы;

2.8.3. Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктатудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

билгеләнмәгән рәвешле гариза тапшырылуы;

дөрес итеп рәсмиләштерелмәгән гариза тапшырылуы;

гаризаның вәкаләтле булмаган юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан бирелүе;

тулы булмаган документлар комплектын бирү;

гаризаның әлеге рөхсәтне алучы булып тормаган шәхси эшкуар яисә юридик зат тарафыннан тапшырылуы;

әзер рөхсәтнең алынмавы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.4. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда яки Порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре.

Рөхсәт биргән өчен түләү 400 сум тәшкил итә.

Рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштергән өчен түләү 400 сум тәшкил итә.

Рөхсәт дубликатын биргән өчен түләү 200 сум тәшкил итә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр.

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп.

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

Рөхсәт алу буенча кәгазьдә гариза тапшыру, чират булганда – иң күбе 15 минут.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да.

Министрлыкка гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

Порталга һәм Бердәм порталга электрон рәвештә кергән гариза, Порталда яки Бердәм порталда рәсми мөрәҗәгатьләр автомат рәвештә теркәлмәгән очракта, Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр белән җиһазландырылган Министрлык биналарында һәм бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла:

а) һаваны кондиционерлау системасы белән;

б) янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;

в) Татарстан Республикасының дәүләт интеграцияле телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмат киоскысы белән;

г) документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар белән;

д) мәгълүмат стендлары белән.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алу шартлары;

б) объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу, шулай ук аларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

в) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итә алу функциясе нык бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм объектларда аларга ярдәм күрсәтү;

г) инвалидларның объекттан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

д) инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

е) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка сукырларны озата йөри торган этне кертү;

ж) хезмәт күрсәтүдә катнаша торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы.

Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Министрлыкның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен белгечләрнең кирәкле санда булуы;

3) район пунктларында, КФҮ, ерактагы эш урыны аша һәм электрон рәвештә Портал яки Бердәм портал аша гариза бирү мөмкинлеге;

4) район пунктларында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге;

5) документларны кабул итү башкарыла торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

6) инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;

7) мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә Министрлыкның мәгълүмат ресурсларында, Порталда һәм Бердәм порталда дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы;

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

3) Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

4) дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуларга карата нигезле шикаятьләр булу.

Мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

гариза белән документларны почта аша җибәргәндә, – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

гаризаны Портал яки Бердәм портал аша тапшырган очракта – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Мөрәҗәгать итүче белән эшләү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, Портал, Бердәм портал, КФҮ яисә КФҮнең ерактагы эш урыны аша алырга мөмкин (дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза КФҮ аша бирелгән очракта).

Дәүләт хезмәте экстриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Комплекслы рәсми мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Порталда яки Бердәм порталда урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны, Портал яисә Бердәм портал аша тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Министрлыкта яки район пунктында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга;

д) Портал яки Бердәм портал, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Порталда яки Бердәм порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Гаризаны электрон рәвештә формалаштырганда мөрәҗәгать итүчегә түбәндәге мөмкинлекләр тәэмин ителә:

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән электрон формага ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон формага элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

ИАБС федераль дәүләт мәгълүмат системасында булмаган мәгълүматларга кагыла

торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Порталда яки Бердәм порталда басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон форма кырларын тутыру;

элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

мөрәҗәгать итүченең Порталда яки Бердәм порталда элек бирелгән гаризаларны карау мөмкинлеге бар.

Гаризаны җибәргән вакытта, мөрәҗәгать итүченең шәхесе исәпкә алу язуын активлаштырганда билгеләнгән булу шарты белән, гади электрон имза кулланыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Портал яки Бердәм портал, КФҮ элемтә үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Портал яки Бердәм портал аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) Рөхсәт бирү:

а) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

б) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

в) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

д) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

2) Рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү:

а) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

б) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

в) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

д) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

3) Рөхсәт дубликаты бирү:

а) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

б) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

в) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

д) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

4) Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату:

а) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

г) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

5) Техник хатаны төзәтү:

а) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

в) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

5) Бирелгән рөхсәтләрнең бердәм реестрыннан өземтә;

а) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

в) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче бүлеккә, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына (алга таба – район пункты), КФҮ яисә КФҮ ерактагы эш урынына шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә (мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон буенча мөрәҗәгать иткән очракта) яки мөрәҗәгать алынган көннән соң дүрт эш көне эчендә (мөрәҗәгать итүче почта һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать иткән очракта) гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәкнең http ://mfc16.tatarstan.ru сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультация һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән кәгазь чыганакта, электрон рәвештә Портал, Бердәм портал аша яисә заказлы почта юлламасы белән, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән, Бүлеккә, район пункты белгеченә, КФҮ яисә КФҮ ерактагы эш урыны аша гариза тапшыра (җибәрә).

Гаризаны кәгазь чыганакта җибәргән очракта, гаризага мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документларның күчермәләре теркәлә.

Гаризаны Портал, Бердәм портал аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Порталда яки Бердәм порталда авторизацияләнә;

Порталда яки Бердәм порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә;

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгеле);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгеле);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Регламентның әлеге пунктында билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.3.2. Гариза район пунктына тапшырылган очракта, район пункты белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза белән документларны кабул итә;

тикшерә:

- документларның тупланышын;

- гариза формасы нигезендә гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүматның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) булуына карата гаризаны тутыру тулылыгын;

- тапшырылган гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) һәм тапшырылган документлар тупланмасында булган мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) туры килүен;

гаризадан һәм теркәп тапшырылган документлардан мәгълүматны Портал яки Бердәм портал аша формалар буенча электрон рәвешкә күчерә.

Район пункты белгече гаризаны гаризаларны теркәү журналында терки һәм мөрәҗәгать итүченең гаризасын һәм документларын электрон формада Портал яки Бердәм портал аша, документларны кабул итү яки документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен, Министрлыкка җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, район пункты белгече шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында Министрлык тарафыннан кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм гаризаны һәм документларны аңа кире кайтара.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Министрлыкка җибәрелгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Гаризаны турыдан-туры Министрлыкка тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүчедән гариза шәхсән кәгазь чыганакта, КФҮ, ерактагы эш урыны аша, Портал яки Бердәм портал аша электрон рәвештә  яисә почта аша заказлы почта юлламасы белән

алынган очракта, Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза белән документларны кабул итә;

тикшерә:

- документларның тупланышын;

- гариза формасы нигезендә гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүматның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) булуына карата гаризаны тутыру тулылыгын;

- тапшырылган гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) һәм тапшырылган документлар тупланмасында булган мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) туры килүен;

кәгазь чыганакта яисә КФҮ, ерактагы эш урыны аша алынган гаризадагы белешмәләрне Портал яисә Бердәм порталның эчке контурына формаларга туры китереп, электрон рәвешкә күчерә.

Бүлек белгече документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, Бүлек белгече гаризаны гаризаларны теркәү журналында терки, аннан соң әлеге Регламентның 3.3.5 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Район пунктыннан гариза алынган очракта, әлеге Регламентның 3.3.5 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, Бүлек белгече:

гариза Министрлыкка кәгазь чыганакта КФҮ аша, ерактагы эш урыны, кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы юллама ярдәмендә яисә Портал яки Бердәм портал аша электрон формада тапшырылган очракта мөрәҗәгать итүчегә (гариза тапшыру ысулына карап), әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасындагы форма буенча карар күчермәсен юллап, документларны кабул итүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар; мөрәҗәгать итүчегә (аның законлы вәкиленә) баш тарту сәбәпләрен дәлилле нигезләп һәм конкрет норматив хокукый актларга сылтама ясап, документларны кабул итүдән баш тарту турында һәм министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) имзалау өчен юнәлдерелгән белдерү.

3.3.4. КФҮ хезмәткәре, КФҮ ерактагы эш урыны хезмәткәре түбәндәгеләрне башкара:

гариза белән документларны кабул итә;

тикшерә:

- документларның тупланышын;

- гариза формасы нигезендә гаризада күрсәтелергә тиешле мәгълүматның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) булуына карата гаризаны тутыру тулылыгын;

- тапшырылган гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткеч-ләрнең) һәм тапшырылган документлар тупланмасында булган мәгълүматларның (белешмәләрнең, күрсәткечләрнең) туры килүен.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар.

КФҮ һәм ерактагы эш урыны аша гаризаны теркәү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны кабул итү өлешендә) билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.3.5. КФҮ хезмәткәре, КФҮ ерактагы эш урыны хезмәткәре гариза һәм документларны Министрлыкка җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.6. Министрлык әлеге Регламентның 3.3.3, 3.3.8, 3.3.11 - 3.3.16 пунктлары нигезендә процедураларны гамәлгә ашырганнан соң кабул ителгән карар турында КФҮ хәбәр итә.

3.3.7. КФҮ хезмәткәре, КФҮ ерактагы эш урыны хезмәткәре, Министрлыктан мәгълүмат алынган очракта, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Министрлыктан мәгълүмат алынган көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.3.8. Министр (министрның вәкаләтле урынбасары) әлеге Регламентның 10 нчы

кушымтасы нигезендә баш тарту сәбәпләре дәлилле нигезләнгән һәм норматив хокукый актларга сылтама ясалган документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны имзалый һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Рөхсәт бирү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документларны кабул иткән көннән башлап ике эш көне эчендә Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (гариза тапшыру ысулына карап), әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасындагы форма буенча, баш тарту сәбәпләрен дәлилле нигезләп һәм мондый баш тарту нигезләре булган норматив хокукый актларның кушымталарына һәм башка документларга сылтама ясап, яки электрон формада, гариза бирү ысулына карап, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар күчермәсен юллап, кабул ителгән карар хакында хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасындагы форма буенча, баш тарту  сәбәпләрен дәлилле нигезләп һәм норматив хокукый актларның кушымталарына һәм башка документларга сылтама  ясап, документларны кабул итүдән баш тарту турында имзаланган һәм мөрәҗәгать итүчегә (аның законлы вәкиленә) бирелгән яки җибәрелгән карар.

Мөрәҗәгать итүче, документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең эчтәлеген язмача аңлатып карар алган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпне юкка чыгарып, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән яңадан гариза бирә ала.

3.3.9. Гариза электрон формада алынган очракта, белешмәләр бирү турында гариза формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – СМЭВ) аша җибәрү автомат рәвештә гамәлгә ашырыла һәм Бүлек белгече тарафыннан түбәндәгеләргә җибәрелә:

Россия Федераль салым хезмәте органнарына;

Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенә;

Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе органнарына;

Россия Эчке эшләр министрлыгы органнарына.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.3.10. Мәгълүмат белән тәэмин итүче, СМЭВ аша кергән гаризалар нигезендә, соратып алына торган документларны (белешмәләрне) бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Юридик затларның яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүченең юридик зат яки шәхси эшкуар сыйфатында гамәлдәге статусы турында белешмәләрне үз эченә алган мәгълүматлар.

3.3.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Алынган мәгълүматлар нигезендә Бүлек белгече:

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

әлеге Регламентның 12 нче кушымтасындагы форма буенча рөхсәт бирү турында боерык проектын һәм рөхсәт бирү турында карар проектын яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентның 11 нче кушымтасындагы форма буенча рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

рөхсәт бирү турында боерык проектын, рөхсәт бирү турында карар проектын яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектын  министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) имзалау өчен юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) имзалау өчен юнәлдерелгән проектлар.

3.3.12. Министр (министрның вәкаләтле урынбасары) рөхсәт бирү турында боерык проектын, рөхсәт бирү турында карар проектын яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерык проектын һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проектын имзалый. Имзаланган документлар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура проектлар министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) имзалау өчен кертелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү турында имзаланган боерык һәм рөхсәт бирү турында карар яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында имзаланган боерык һәм рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар.

3.3.13. Бүлек белгече:

рөхсәт бирү турында боерыкны һәм рөхсәт бирү турында карарны (рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерыкны һәм баш тарту сәбәпләрен дәлилле нигезләп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында имзаланган карарны) оештыру үсеше бүлегенә теркәү өчен тапшыра;

мөрәҗәгать итүчегә, рөхсәт бирү турында яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар күчермәсен җибәрү юлы белән, кабул ителгән карар турында хәбәр итә (гариза бирү ысулына карап);

рөхсәт әзерли.

Процедураның нәтиҗәсе: оештыру үсеше бүлегенә теркәү өчен тапшырылган документлар, әзерләнгән рөхсәт.

3.3.14. Оештыру үсеше бүлеге белгече имзаланган рөхсәт бирү турында боерыкны, рөхсәт бирү турында карарны яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында боерыкны һәм баш тарту сәбәпләрен дәлилләп, рөхсәт бирүдән баш тарту турында карарны терки.

Район пункты аша рөхсәт бирү турында гариза кергән очракта, Бүлек белгече рөхсәт бирү турындагы боерыкны, рөхсәт бирү турындагы карарны яки рөхсәт бирүдән баш тарту турындагы карарны, мөрәҗәгать итүчегә тапшыру өчен, электрон элемтә чаралары белән район пунктына җибәрә. Вәкаләтле хезмәткәр рөхсәт бирү турында боерык нигезендә, мөрәҗәгать итүчегә тапшыру өчен, рөхсәт әзерли.

Процедураның нәтиҗәсе: район пунктына җибәрелгән, теркәлгән документлар (гариза район пункты аша кергән очракта).

3.3.15. Район пункты белгече рөхсәт бирү турындагы боерык нигезендә, мөрәҗәгать итүчегә тапшыру өчен, рөхсәт әзерли.

Әлеге Регламентның 3.3.10-3.3.12 пунктларында билгеләнә торган процедуралар министр (министрның вәкаләтле урынбасары) тарафыннан документларга кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: әзерләнгән рөхсәт.

3.3.16. Оештыру үсеше бүлеге белгече, гариза бирү ысулына карап, мөрәҗәгать итүче таләбе буенча, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 11 нче кушымтадагы форма буенча рөхсәт бирүдән баш тарту турында карарны тапшыра яисә гаризада күрсәтелгән адрес буенча мөрәҗәгать итүчегә тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы белән җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар баш тарту турындагы карарны рәсмиләштергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән рөхсәт бирүдән (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән) баш тарту турында карар яисә электрон рәвештә җибәрелгән карар.

3.3.17. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече, район пункты белгече, рөхсәт алу өчен гариза бирелгән транспорт чарасын закон таләпләренә туры китереп тикшерә, документларның төп нөсхәләрен гаризага теркәп тапшырылган күчермәләре белән чагыштыра, рөхсәт биргән өчен түләү турындагы белешмәләрне тикшерә, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рәсмиләштерелгән рөхсәтне бирелгән рөхсәтләр журналында рөхсәтне алу турында имзалатып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: карап тикшерелгән транспорт чарасы, документларның чагыштырылган төп нөсхәләре һәм күчермәләре, бирелгән рөхсәт.

3.3.18. Бүлек белгече, район пункты белгече:

Порталның яки Бердәм порталның эчке контурында рөхсәт бирү турындагы гариза статусын үзгәртә;

рөхсәт эшен формалаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт бирелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза статусын актуальләштерү; формалаштырылган рөхсәт эше.

3.3.19. Бүлек белгече Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелгән рөхсәтләр реестрын (алга таба – Бирелгән рөхсәтләр реестры) чыгара һәм аны мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторына җибәрә.

Мәгълүматлаштыру һәм мәгълүмат секторы белгече бирелгән рөхсәтләр турында белешмәләрне Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән яңарта.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Порталның яки Бердәм порталның эчке контурында рөхсәт бирү турындагы гариза статусы үзгәргән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәтләрнең яңартылган Реестры.

3.4. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү.

3.4.1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Бүлеккә, район пунктына яисә КФҮ шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече, район бүлеге белгече, КФҮ хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә (мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон буенча мөрәҗәгать иткән очракта) яки мөрәҗәгать алынган көннән соң дүрт эш көне эчендә (мөрәҗәгать итүче почта һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать иткән очракта) гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультация һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

3.4.2. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле):

юридик затны үзгәртеп корган очракта;

юридик затның атамасын, аның урнашу урынын үзгәрткән очракта;

шәхси эшкуарның яшәү урынын, исемен, фамилиясен һәм атасының исемен (әгәр булса), шәхесен раслаучы документ белешмәләрен үзгәрткән очракта;

җиңел такси буларак файдаланыла торган транспорт чарасының дәүләт теркәү билгесен үзгәрткәндә, шәхсән кәгазь чыганакта, электрон рәвештә Портал яки Бердәм портал аша яисә, кулга тапшыру турында белдереп, почта буенча заказлы почта юлламасы белән, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гаризаны Бүлеккә, район пункты белгеченә яки КФҮ тапшыра (җибәрә).

3.4.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризаны кабул итү, теркәү, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерү әлеге Регламентның 3.3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.4. Ведомствоара оешмаларга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү һәм алардан җавап алу әлеге Регламентның 3.3.9, 3.3.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Алынган мәгълүматлар нигезендә Бүлек белгече:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән гаризаны һәм документларны, мөрәҗәгать итүченең рөхсәт эшендә булган белешмәләрне исәпкә алып, карап тикшерә;

әлеге гаризада һәм аңа теркәп тапшырылган документлардагы яңа белешмәләрнең дөреслеген тикшерә;

рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү яисә аны үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итә;

әлеге Регламентның 12 нче кушымтасындагы форма буенча рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында боерык проектын һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар проектын яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Регламентның 11 нче кушымтасындагы форма буенча рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык проектын яки рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

боерык һәм карар проектын раслау өчен министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) имзалау өчен юнәлдерелгән документлар проектлары.

3.4.6. Министр (министрның вәкаләтле урынбасары) рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында боерыкны һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карарны яисә рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерыкны һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турындагы карарны имзалый һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документлар имзалау өчен алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында имзаланган боерык, рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар яисә рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар.

3.4.7. Бүлек белгече:

рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында боерыкны һәм рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карарны (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерыкны һәм баш тарту сәбәпләрен дәлилле нигезләп, рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында имзаланган карарны) оештыру үсеше бүлегенә теркәү өчен тапшыра;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура министр (министрның вәкаләтле урынбасары) тарафыннан документлар имзаланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында теркәлгән боерык, рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык һәм, баш тарту сәбәпләрен дәлилле нигезләп, рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында имзаланган карар), әзерләнгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт яисә әлеге Регламентның 3.3.16 пункты нигезендә рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында җибәрелгән карар.

3.4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәтне, рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризага теркәлгән документларның төп нөсхәләрен яисә мондый документларның нотариаль таныкланган күчермәләрен күрсәткән очракта, элегрәк бирелгән рөхсәтне мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире кайтару шарты белән, бирелгән рөхсәтләр журналында имзалатып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә

башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән рөхсәт.

3.4.9. Статусны үзгәртү һәм бирелгән рөхсәтләр Реестрын яңарту әлеге Регламентның 3.3.18 һәм 3.3.18 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт дубликаты бирү.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү әлеге Регламентның 3.4.1 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле), рөхсәтне югалту сәбәпле яисә аның бозылуы нәтиҗәсендә (рөхсәтне теркәп), мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ күчермәсен теркәп, Бүлеккә, район пункты белгеченә яисә КФҮ шәхсән кәгазь чыганакта яисә почта аша (тапшыру турында белдерү белән заказлы почта юлламасы ярдәмендә) рөхсәт дубликаты бирү турында гариза тапшыра.

3.5.3. Рөхсәт дубликаты бирү турындагы гаризаны кабул итү, теркәү, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерү әлеге Регламентның 3.3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла. Гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигез булмаса, әлеге Регламентның 3.3.9 пунктында каралган процедуралар үткәрелә.

3.5.4. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм җибәрү.

Ведомствоара оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү һәм алардан җавап алу әлеге Регламентның 3.3.9, 3.3.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.5.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Бүлек белгече:

әлеге Регламентка 12 нче кушымта нигезендә рөхсәт дубликаты бирү турында боерык, рөхсәт дубликаты бирү турында карар проекты әзерли;

әзерләнгән документларның проектларын министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) имзалау өчен юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) имзалау өчен юнәлдерелгән документлар проектлары.

3.5.6. Министр (министрның вәкаләтле урынбасары) рөхсәт дубликаты бирү турында боерыкны, рөхсәт дубликаты бирү турында карарны имзалый. Имзаланган боерык һәм карар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документлар имзалау өчен алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган документлар.

3.5.7. Бүлек белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә;

«дубликат» һәм «рөхсәтнең төп нөсхәсе гамәлдә түгел дип таныла» тамгалары язылган рөхсәт дубликатын әзерли.

Рөхсәт дубликаты бирү турында гариза район пункты аша алынган очракта, Бүлек белгече рөхсәт дубликаты бирү турында боерыкны һәм карарны электрон элемтә чаралары белән район пункты белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече рөхсәт дубликатын мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт дубликатын алу турында бирелгән рөхсәтләр турында журналда имзалатып, мөрәҗәгать bn]xtyt; (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документның төп нөсхәсе күрсәтелгән очракта бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәт дубликаты.

3.5.9. Статусны үзгәртү һәм бирелгән рөхсәтләр Реестрын яңарту әлеге Регламентның 3.3.18 һәм 3.3.19 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6. Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату.

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында гаризаны Бүлеккә, район пункты белгеченә яисә КФҮ кәгазь чыганакта шәхсән яисә почта буенча (кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән) җибәрә.

3.6.2. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турындагы гаризаны кабул итү, теркәү, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерү әлеге Регламентның 3.3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Бүлек белгече рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында боерык проектын әзерли һәм министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) раслау өчен җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга (министрның вәкаләтле урынбасарына) раслау өчен җибәрелгән рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында боерык проекты.

3.6.4. Министр (министрның вәкаләтле урынбасары) рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында боерыкны раслый. Имзаланган документлар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында имзаланган боерык.

Әлеге Регламентның 3.6.3 һәм 3.6.4 пунктларында билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында боерыкны теркәү өчен оештыру үсеше бүлегенә тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: оештыру үсеше бүлегенә җибәрелгән документлар.

3.6.6. Оештыру үсеше бүлеге белгече рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында боерыкны терки.

Әлеге Регламентның 3.6.5 - 3.6.6 пунктларында билгеләнә торган процедуралар министр (министрның вәкаләтле урынбасары) тарафыннан боерыкка кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктату турында теркәлгән боерык.

3.6.7. Бирелгән рөхсәтләр реестрын актуальләштерү һәм яңарту әлеге Регламентның 3.3.18 һәм 3.3.19 пунктчалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата булуы ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче (аның законлы вәкиле) Бүлеккә, КФҮ аша, еракатагы эш урыны аша шәхсән кәгазь чыганакта яисә почта аша кулга тапшыру турында белдерүле заказлы юллама белән түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Регламентка 9 нчы кушымта нигезендәге форма буенча техник хатаны төзәтү турында гариза;

бирелгән, техник хатасы булган рөхсәт;

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документ;

мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ.

3.7.2. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Министрлыкның оештыру үсеше бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә электрон документ әйләнеше системасында терки һәм аларны гариза алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә Бүлеккә тапшыра.

КФҮ хезмәткәре, ерактагы эш урынында гаризалар кабул итүне алып баручы хезмәткәр, КФҮ эш регламентында каралган процедураларны башкара һәм Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин гариза КФҮ теркәлгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хатаны төзәтү турында гаризаны Министрлыкка җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Техник хатаны төзәтү турында гариза алынган очракта, Бүлек белгече Министрлык карамагындагы документларны чагыштыра һәм техник хата булуы расланган очракта, рөхсәт әзерли һәм мөрәҗәгать итүчегә аны алу мөмкинлеге турында мөмкин булган теләсә нинди ысул белән хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, Бүлек белгеченә техник хата турында гариза кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән рөхсәт һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.7.4. Бүлек белгече бирелгән рөхсәттә техник хата булуын ачыклаган очракта, Министрлыкта булган документлар чагыштырыла һәм техник хата булуы расланган очракта, рөхсәт әзерләнә һәм мөрәҗәгать итүчегә теләсә нинди ысул белән, Бүлеккә техник хатасы булган рөхсәтнең төп нөсхәсен тапшырган очракта, аны алу мөмкинлеге турында хәбәр ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, техник хата ачыкланган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әзерләнгән рөхсәт һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.7.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече, район пункты белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) рөхсәтне рөхсәт алу турында имзалатып тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле)

килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән рөхсәт.

Район пунктында бирелгән рөхсәттәге техник хатаны төзәтү процедуралары әлеге Регламентның 3.7.1 - 3.7.5 пунктлары нигезендә рөхсәтнең төп нөсхәсе бирелгән урын буенча гамәлгә ашырыла.

3.8. Бирелгән рөхсәтләр реестрыннан өземтә.

3.8.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) бирелгән рөхсәтләр реестрыннан өземтә (алга таба – өземтә) алу өчен, әлеге Регламентка 13 нче кушымтадагы форма буенча өземтә бирү турындагы гаризаны Министрлыкка шәхсән кәгазь чыганакта, КФҮ аша, ерактагы эш урыны аша, кулга тапшыру турында белдереп, почта буенча заказлы почта юлламасы белән җибәрә яисә Портлда яисә Бердәм порталда шәхси кабинетта электрон формада гариза формалаштыра.

3.8.2. Министрлыкның оештыру үсеше бүлеге белгече өземтә бирү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны электрон документ әйләнеше системасында терки һәм аны гариза алынган вакыттан башлап бер эш көне эчендә Бүлеккә тапшыра.

КФҮ хезмәткәре, ерактагы эш урынында гаризалар кабул итүне алып баручы хезмәткәр, КФҮ эш регламентында каралган процедураларны башкара һәм Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, ләкин гариза КФҮ теркәлгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, өземтә бирү турында гаризаны Министрлыкка җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: өземтә бирү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

Өземтә бирү турында гариза алынган очракта, Бүлек белгече Порталның яки Бердәм порталның эчке контурында электрон формада гариза формалаштыра һәм, гариза бирү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчегә өземтәне алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, Бүлек белгеченә өземтә бирү турында гариза кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: формалаштырылган өземтә һәм мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның законлы вәкиленә), гариза бирү ысулына карап, әлеге Регламентның 14 нче кушымтасындагы форма буенча өземтәне тапшыра яисә, кулга тапшыру турында белдереп, почта аша заказлы юллама итеп җибәрә яки, гариза бирү ысулына карап, электрон формада юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, өземтә бирү турында гариза кергән

көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көнлек срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән яки җибәрелгән өземтә.

3.9. Административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре.

3.9.1. Электрон формада түбәндәге административ процедуралар гамәлгә ашырылырга мөмкин:

Рөхсәт бирү өчен гариза һәм документларны кабул итү;

Гаризаны һәм тапшырылган документларны карау;

Бирелгән рөхсәтләрне исәпкә алу.

3.9.2. Гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документларны мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламент таләпләрен үтәп, электрон формада тапшырырга хокуклы.

Гариза электрон формада тапшырылган очракта, гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гаризаны имзалаган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

3.9.3. Гаризага мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге беркетелергә тиеш.»;

Регламентның 6 нчы бүлеген гамәлдән чыккан дип танырга;

Регламентка 1 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта»;

Регламентка 2 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта»;

Регламентка 3 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта»;

Регламентка 4 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта»;

Регламентка 5 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ

регламентына 5 нче кушымта»;

Регламентка 6 нчы кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта»;

Регламентка 7 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта»;

Регламентка 8 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта»;

Регламентка 9 нчы кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 291-90-10 | Ministr.Priemnaya@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 291-90-13 | Priemnaya.02@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Транспорт идарәсе җитәкчесе | 291-91-12 | Aleksey.Sidorov@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе | 264-76-62 | pisma@tatar.ru»; |

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 10 нчы кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 10 нчы кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы

Кемгә: Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең)
фамилиясе, исеме, атасының исеме
Шәхесне раслаучы документ исеме, сериясе, номеры,
бирелгән датасы, кем тарафыннан бирелгән,
Оешма исеме, адресы
Элемтә өчен телефон, электрон почта,
Төп дәүләт теркәве номеры, шәхси тәңгәллек саны

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында

**КАРАР**

кемнән Хезмәт күрсәтү өчен гариза тапшыру көне № Хезмәт күрсәтү турындагы гаризаның номеры

Алынган гариза нигезендә, ул теркәлде: Хезмәт күрсәтү турында гариза тапшыру көне Хезмәт күрсәтү турында гариза номеры, Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар карар кабул ителде, нигезе: әлеге Регламентның 2.7 пунктындагы нигезләр

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен бетерү өчен кирәкле мәгълүмат, шулай ук, булган очракта, башка өстәмә мәгълүмат.

Сез Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга карата, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына шикаять җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Вәкаләтле затның вазыйфасы Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме

| | | |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | Электрон имза сертификаты турында белешмәләр | (тулы имза)»; |

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 11 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 11 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы

Кемгә: Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме
Шәхесне раслаучы документ исеме, сериясе, номеры, бирелгән датасы, кем тарафыннан бирелгән,
Оешма исеме, адресы
Элемтә өчен телефон, электрон почта,
Төп дәүләт теркәве номеры, шәхси тәңгәллек саны

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга рөхсәт бирүдән (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән) баш тарту турында

**КАРАР**

№ боерык номеры боерык датасы

Теркәлгән Хезмәт күрсәтү турында гариза тапшыру көне Хезмәт күрсәтү турында гариза номерыгаризаны карау нәтиҗәләре буенча, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы

федераль законның (алга таба – 69-ФЗ номерлы федераль закон) 9 статьясының 2.1 өлешендә каралган нигезендә түбәндәгечә карар кабул ителде:
Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен әлеге транспорт чарасына (чараларына) рөхсәт (алга таба – рөхсәт) бирүдән (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерүдән) баш тарту турында:
маркасы, моделе, дәүләт теркәү билгесе, нигезләре: әлеге Регламентның 2.8 пунктындагы нигезләр. Җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташуга рөхсәт бирүдән баш тарту сәбәпләрен аңлату: ___________________________________

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң, Сез 69-ФЗ номерлы федераль законның 9 статьясындагы 1.1 һәм 1.2 өлешләрендә каралган документларны теркәп, рөхсәт бирү турында гариза белән кабат Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга карата, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына шикаять җибәрү юлы белән, шулай ук суд тәртибендә судка кадәр тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

| Вәкаләтле затның вазыйфасы | | Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | Электрон имза сертификаты турында белешмәләр | (тулы имза)»; |

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 12 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 12 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы

Кемгә: Мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме
Шәхесне раслаучы документ исеме, сериясе, номеры, бирелгән датасы, кем тарафыннан бирелгән,
Оешма исеме, адресы
Элемтә өчен телефон, электрон почта,
Төп дәүләт теркәве номеры, шәхси тәңгәллек саны

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) турында
КАРАР

№Боерык номеры боерык датасы

Теркәлгән Хезмәт күрсәтү турында гариза тапшыру көне Хезмәт күрсәтү турында гариза номерыгаризаны карау нәтиҗәләре буенча, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 69-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү)» (алга таба – рөхсәт) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында карар кабул ителде.

Әлеге транспорт чарасына (чараларына) рөхсәт (рөхсәтләр) бирергә:
- маркасы, моделе, дәүләт теркәү билгесе

Вәкаләтле затның вазыйфасы Вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, ата исеме

(вазыйфа) | Электрон имза сертификаты турында белешмәләр | (тулы имза)»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 13 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 13 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелгән рөхсәтләр реестрыннан өземтә бирү турында гариза**

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелгән рөхсәтләр реестрыннан өземтә бирүегез турында үтенәм

| т/с | Транспорт чарасының маркасы, моделе | Дәүләт теркәвенә алу тамгасы |
|---|---|---|
| 1 | | |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | | |

Юридик зат җитәкчесе (вәкиле) /
Шәхси эшкуар (аның вәкиле)
________________________________
(имза, тулы имза, дата)»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 14 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирү (рөхсәтне үзгәртеп рәсмиләштерү, рөхсәт дубликаты бирү) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 14 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү
һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелгән
рөхсәтләр реестрыннан

**ӨЗЕМТӘ**

Рөхсәт бирү датасы №Рөхсәт номеры

Әлеге өземтә Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен рөхсәт бирелүен раслый һәм пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен җиңел такси сыйфатында кулланыла торган транспорт чарасы турында әлеге белешмәләрне үз эченә ала:

маркасы, моделе, дәүләт теркәү билгесе

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогы Рөхсәтнең гамәлдә булу срогы

| т/с | Атамасы | Эчтәлек |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Рөхсәт хуҗасы турында мәгълүмат | | |
| 1 | Юридик затның оешу-хокук формасы, исеме/ шәхси эшкуарның ФИА | |
| 2 | ОГРН/ОГРНИП | |
| 3 | Салым түләүченең тәңгәллек номеры | |
| 4 | Юридик затның урнашу урыны адресы/шәхси эшкуарның теркәлү адресы | |
| 5 | Шәхесне раслаучы документ исеме | |
| 6 | Сериясе, номеры, бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән | |

Өземтә формалаштырылды Дәүләт хакимияте органы исеме

җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирелгән рөхсәтләр реестрыннан белешмәләр бирүгә вәкаләтле Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы исеме

| ________________ | _______________ | ________________________________ |
|---|---|---|
| Җаваплы затның вазыйфасы | имза | фамилиясе һәм инициаллары |

| Электрон имза сертификаты турында белешмәләр». |
|---|